Республика Татарстан

Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башлыгы

ул. А.Валеева, д. 53, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423321

А.Валеев урамы, 53нче йорт, Илбәк авылы,
Азнакай районы, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» июнь2017 ел. № 4

Азнакай муниципаль районы "Илбәк авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлекнең җирдән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами
тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль берәмлегенең «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл Советының 18.04.2012 ел, № 35 карары белән расланган (16.02.2015 ел, № 114, 05.09.2015 ел, № 132 карарлар редакциясендә) карар бирәм::

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә гавами тыңлауларны оештыручы;

- үткәрү вакыты – 2017 елның 01 июленнән 2017 елның 01 сентябренә кадәр 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;

– уздыру урыны-Илбәк авылы, ә. Вәлиев ур., 50 й.;

- 2017 елның 01 сентябренә кадәр фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес – Илбәк авылы, ә.Вәлиев урамы, 53 йорт, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлегендә җирдән файдалану

һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru/ / урнаштытырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина